**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6325**
**05.12.2019**

Башкарма комитетның
аерым карарлары үз көчен
югалтуны тану турында

«Дәүләт һәм муниципаль милекне приватизацияләү турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 32.1 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 3.18, 5.21, 5.23 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның аерым карарлары үз көчен югалтуны танырга:

1) 2006 елның 18 ноябрендә «Челнинские известия» газетасының 218-220 номерларында басылып чыккан «Аукционда муниципаль милекне сату турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 13 ноябрендәге 4341 номерлы;

2) 2009 елның 23 сентябрендә «Челнинские известия» газетасының 182-183 номерларында басылып чыккан «Аукционда муниципаль милекне сату турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 16 сентябрендәге 4003 номерлы;

3) «Башкарма комитет Җитәкчесенең «Аукционда муниципаль милекне сату турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 13 ноябрендәге 4341 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 13 сентябрендәге 5810 номерлы карары;

4) 2014 елның 1 августында «Челнинские известия» газетасының 56 номерында басылып чыккан «Башкарма комитет Җитәкчесенең «Аукционда муниципаль милекне сату турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 13 ноябрендәге 4341 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 21 июлендәге 4257 номерлы;

5) 2015 елның 26 июнендә «Челнинские известия» газетасының 46 номерында басылып чыккан «Башкарма комитет Җитәкчесенең «Аукционда муниципаль милекне сату турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 13 ноябрендәге 4341 номерлы карарының 2 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 16 июнендәге 3637 номерлы;

6) 2015 елның 9 сентябрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) басылып чыккан «Башкарма комитет Җитәкчесенең «Аукционда муниципаль милекне сату турында нигезләмәне раслау

хакында» 2006 елның 13 ноябрендәге 4341 номерлы карарының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 4 сентябрендәге 4948 номерлы;

7) 2018 елның 15 августында «Челнинские известия» газетасының 59 номерында, 2018 елның 9 августында Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) басылып чыккан «Башкарма комитет Җитәкчесенең «Аукционда муниципаль милекне сату турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 13 ноябрендәге 4341 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 6 апрелендәге 1890 номерлы;

8) 2019 елның 3 июлендә «Челнинские известия» газетасының 47 номерында, 2019 елның 2 июлендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) басылып чыккан «Аукционда муниципаль милекне сату турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 28 июнендәге 3285 номерлы.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны, шулай ук «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин